РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
УСАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Первомайская, д.4, с. Усали,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422174

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УСАЛИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ

Беренче май ур., 4 нче йорт, Үсәли авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422174

тел.(факс): (85563) 2-74-10; e-mail: Usal.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

**№30** **от 22.11.2018г.**

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Усали авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федраль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставы белән, җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән “19» ноябрь 2018 елдагы № 926 карарны гамәлгә ашыру максатыннан, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыюның әлеге Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз контролемә алам.

Усали авыл җирлеге
Башкарма комитет
җитәкчесе А.И.Зиатдинов

Татарстан
республикасы
Мамадыш муниципаль
районы,Усали авыл
җирлеге башкарма
комитетының 2018
елның 22 ноябрендә
30 № лы карарына 1
нче кушымта

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы,**
**Усали авыл җирлеге гражданнарының**
**үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 18 яшькә җиткән һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы, Усали авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан 2019елның
28 февраленә
кадәр, гражданнарның түбәндәге категорияләреннән тыш,

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала,, аларның җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашу-катнашмавына һәм аларның тавыш бирү барышында белдергән мөнәсәбәтләреннән бәйсез рәвештә түләнә.

3. Түбәндәге игътибарга лаеклы сәбәпләр булганда:
а)вакытлыча хезмәткә ярамаган очракта,
б)эш буенча командировкаларда булу,
гражданнарга гариза нигезендә бер айдан артык булмаган вакытка, түләү кертүне кичектереп тору рөхсәт ителергә мөмкин,

4. Бер тапкыр түләнә торган түләүне башкару турындагы белдерү кәгазе бланкы гражданнар игътибарына муниципаль берәмлекнең мәгълүмат стендларында,Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында бастырып чыгаруһәм халыкка җиткерү Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы уставында билгеләнгән тәртиптә,шулай ук имза куйдырып шәхсән тапшыруяки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

Белдерү кәгазе үз эченә гражданнарның үзара салым акчаларын түләү реквизитларын, бер тапкыр түләнә торган акчаның тулысынча яки киметелгән күләмдәге суммасын, түләү вакытын алырга тиеш.

6. Гражданнардан алынган үзара салым акчалары Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге лицевой счетына күчереләләр.

7. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

8. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

9. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан
Республикасы
Мамадыш муниципаль
районы Усали авыл
җирлеге
башкарма
комитетының 2018
елның 22ноябре 30
нчы № лы карарына 2
нче кушымта

Усали авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләү кертү турында

БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ № _______________

Түләүченең Ф.И.Ә.и. ____________________________________________________

Адрес: Татарстан Республикасы,Мамадыш муниципаль районы, ______________________________________________

Нигезләмә Татарстан Республикасы Мамадыш районы территориаль сайлау комиссиясенең 2018нче елның 19 ноябрендәге 926№лы карары

Сезгә 2019 елның 28 феврале көненә кадәрге вакыт эчендә

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җ ирлеге территориясендә 2018елның 18 ноябрендә узган референдум карары нигезендә

куелган чараны гамәлгә ашыру буенча 400 сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган түләүне түбәндәге реквизитларга күчерергә кирәк:
Кабул итүче як банкы БИК 049205001 НБ РТ Казан шәһәре
Сч. № ________________________________
Кабул итеп алучы
Сч. № 40101810800000010001
ИНН 1626008921
КПП 162601001
КБК 60511714030100000180
ОКАТО 92238890000 ОКТМО 92638490
Түләүнең билгеләнеше

Җитәкче ________________ ______________________________________
М.У. (имза) (тулысынча язылыш)

- - - - - - - - - - - - - - - - - **кисеп алу сызыгы** - - - - - - - - - - - - - - -

Усали авыл җирлеге
бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне
_______________ сум күләмендә түләү турында № ________ белдерү кәгазе.
Түләүченең Ф.И.Ә.и.
____________________________________________________

Адрес:
_________________________________________________________________

Кабул ителде «__» _______________ 20__ ел.
____________________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Белдерү кәгазе түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, түләү кәгазе өлеше (отрывной корешок) тутырыла һәм Усали җирлеге башкарма комитетында кала.*